**Хаялетдинова Динә Гыйбадрахман кызы**
**Яшел Үзән медицина училищесы укытучысы, ветеран**

Хаялетдинова Динә Гыйбадрахман кызы Яшел Үзән медицина училищесында «Микробиология, вирусология, иммунология нигезләре» һәм «Анатомия һәм кеше физиологиясе нигезләре» фәннәрен укыта. Ул үзен югары квалификацияле, хезмәт сөючән һәм инициативалы укытучы итеп танытты. Бөтен һөнәри эшчәнлек дәвамында укытучы һөнәри осталык дәрәҗәсен күтәрү, семинар-киңәшмәләрдә алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү, республика методик берләшмәләрендә һәм түгәрәк өстәлләрендә актив эш алып бара. Укытучы үзе укыта торган дисциплинаны укыту-методик яктан тәэмин итүне камилләштерү өстендә даими рәвештә эшли, укыту-методик комплекслар белән тәэминителеш 100% тәшкил итә. Дәресләрне мавыктыргыч итеп укыта, белем бирү процессына медицинаның яңа казанышларын кертә. Яхшы мөгамәлә, дәрестә студентлар белән даими аралашу, үзенең фәненә карата кызыксыну уята. Традицион һәм инновацион технологияләрне дөрес куллана, актив методларга өстенлек бирә: рольле уеннар, проблемалы укыту, баш мие штурмы. Укытуның интерактив алымнарын куллану студентларда клиник һәм логик фикерләүне үстерүгә, индивидуаль иҗади сәләтләрне тормышка ашыруга ярдәм итә. Студентларның дисциплина буенча белем сыйфаты югары дәрәҗәдә: уртача 91%, өлгереш 100%.

Хаялетдинова Д.Г. һөнәри осталык конкурсларында нәтиҗәле катнаша: 2016 елда Идел буе федераль округының урта медицина һәм фармацевтика белем бирү уку йортлары арасында “Дәвалау эше”, “Шәфкать туташлары эше” белгечлекләре буенча укучыларның аудитор һәм аудитордан тыш эшләре өчен микробиологиядән методик эшләнмәләрнең читтән торып үткәрелгән конкурсында 2 урын, 2015 елда Яшел Үзән медицина училищесы базасында Идел буе федераль округының урта медицина һәм фармацевтика белем бирү уку йортлары укытучылары арасында «Кеше анатомиясе һәм физиологиясе» дисциплинасы буенча «Иң яхшы укыту-методик комплексы» дигән читтән торып төбәкара конкурсны оештыру һәм уздыру эшендә катнашты. Шулай ук 2015 елда Идел буе федераль округының медицина һәм фармацевтика белем бирү уку йортлары студентлары арасында «Микробиология һәм иммунология нигезләре» дисциплинасы буенча олимпиадада катнашу өчен студентны әзерләде. 2017 елда Идел буе федераль округы буенча медицина профилендәге урта һөнәри белем бирү уку йортлары студентлары арасында “Дәвалау эше” белгечлеге буенча «Анатомия һәм кеше физиологиясе» фәненнән, РФнең башка округларын җәлеп итеп, «Умники и Умницы» читтән торып үткәрелгән конкурста катнашырга студентны әзерләде һәм 1 урынны алды. Конкурс Удмуртия Республикасының «Можга медицина көллияте» бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе базасында үткәрелде. 2018 елда Динә Гыйбадрахман кызы әзерләгән студент Идел буе федераль округының урта медицина һәм фармацевтика һөнәри белем бирү уку йортлары студентлары арасында «Анатомия һәм кеше физиологиясе» дисциплинасының тематик блогы буенча “Дәвалау эше” белгечлеге буенча "Бала сәламәтлеге торышының анатомо-физиологик үзенчәлекләре» дигән читтән торып үткәрелгән олимпиадада 3 урынны алды. Олимпиада Удмуртия Республикасының «Удмуртия Республикасы сәламәтлек

саклау министрлыгының Сарапул медицина көллияте» автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында үткәрелде.

Куратор буларак Динә Гыйбадрахман кызы уннан артык төркем шәфкать туташлары һәм фельдшерлар чыгарды. Яхшы оештыру сәләтенә ия, уку төркеменә оста җитәкчелек итә, шул ук вакытта педагогик тактны һәм тормыш зирәклеген күрсәтә. Аның чыгарылыш студентларының белгечлек буенча эшкә урнашуы 90% тәшкил итә. Д.Г. Хәялетдинова киң күзаллау һәм югары иҗат дәрәҗәсе, намуслылык һәм принципиальлек, үз-үзенә һәм студентларга таләпчәнлек белән аерылып тора. Хезмәттәшләре һәм студентлары хөрмәтенә лаек. Училищеның эчке тәртип кагыйдәләрен һәм хезмәт дисциплинасын тайпылышсыз башкара. Д.Г. Хаялутдинованың намуслы эше Яшел Үзән медицина училищесы җитәкчелеге һәм Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан берничә тапкыр бүләкләнде.